Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең
Каменка поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

27 октябрь 2025 ел № 5

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 27 октябрендә 13 сәгать 00 минутта булган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Никольский авыл җирлеге Каменка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту)?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 10 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 8 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 8 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Каменка поселогында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. “Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Никольский авыл җирлеге Каменка поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме: торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту)?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Каменка поселогы, Елга урамы, 11 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Фазлыев